Татарстан Республикасы Ютазы муниипаль районы Ютазы авыл җирлеге Советы

КАРАР №23

Ютазы авылы 2018 елның 30 ноябре

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең 2014 елның 21 ноябреннән булган “Физик затлар милегенә салым турында”гы №24 карарына үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Салым кодексының 399 ст. 2 пункты нигезендә Ютазы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 21.11.2014 елның 21 ноябрендәге «Физик затларның милегенә салым турында" гы № 24 карарына ( 2015 елның 19 августындагы 15 номерлы, 2015 елның 14 октябрендәге 09 номерлы редакциясендә) түбәндәге өстәмәләрне кертергә: Түбәндәге эчтәлектәге пункт өстәргә:
"3.
1 Физик затлар милегенә салым түләүдән түбәндәге затларны азат итәргә:
1) 18 яшькә җитмәгән инвалид балалары булган гражданнарны;
2) 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган аз керемле гаиләләрдәге гражданнарны. Салым түләүдән гражданнар салым органнарына ел саен раслаучы документлар тапшырган очракта азат ителәләр».
2. Әлеге карар хакимят бинасының мәгълүмат стендында һәм Интернет мәгълүматтелекоммуникация челтәрендәге Ютазы муниципаль районының http://jutaza.tatar.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында, Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясындагы 3 һәм 4 пунктлары нигезендә урнаштырып, халыкка рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнвар үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Ютазы авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Сафиуллина